**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Иске Казиле авыл җирлеге Советы**

**КАРАРЫ**

3 май 2023 ел № 78

Җирле салымнар суммасы буенча бурычн түләтүне өметсез дип тануга өстәмә нигезләр билгеләү турында

Россия Федерациясе Салым кодексының 59 статьясының 3 пункты, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Иске Казиле авыл җирлеге Советы Уставы нигезендэ Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Иске Казиле авыл җирлеге Советы Карар кабул итте:

1. Җирле салымнар суммалары буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләргә:

1) физик затның үлеменнән соң өч еллык срокның тәмамлануы яки аны гражданлык процессуаль законнары нигезендә билгеләнгән тәртиптә үлгән дип игълан ителүе, әгәр варислар закон буенча да, васыять буенча да булмаса, яки варисларның берсе дә мирас алудан читләштерелмәсә, яки варисларның берсе дә мирас алудан баш тартса, яки аларның барысы да мирас алудан баш тартса, һәм аларның берсе дә башка кеше файдасына баш тартуын күрсәтмәсә;
2) салым түләүче гражданнарның- физик затнын стационар социаль хезмәт күрсәтүне гамәлгә ашыручы оешмада булуы;
3) салым салу объекты булган милеккә милек хокукы туктатылган көннән өч еллык срокның тәмамлануы;
4) җирле салымнарны һәм җыемнарны түләү буенча бурыч барлыкка килгән көннән алып өч еллык срокның тәмамлануы.

2. Иске Казиле авыл җирлеге Советының 2019 елның 17 октябрендәге 119 номерлы, 2019 елның 30 декабрендәге 128 номерлы, 2022 елның 23 декабрендәге 67 номерлы “Бурычларны, пенялар буенча бурычларны һәм җирле салымнар буенча штрафларны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында»гы карарларны үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында игълан итәргә:

1) Татарстан Республикасы, Кама Тамагы муниципаль районы, Иске Казиле авылы, Һади Такташ ур., 4;
2) Татарстан Республикасы, Кама Тамагы муниципаль районы, Каратал авылы, Күпер урамы, 5;
3) Татарстан Республикасы, Кама Тамагы муниципаль районы, Атабай авылы, Үзәк урамы, 14; шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыккач үз көченә керә һәм 2023 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә үз көчен җәелдерә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Кама Тамагы муниципаль районының
Иске Казиле авыл җирлеге башлыгы,
Кама Тамагы муниципаль районының
Иске Казиле авыл җирлеге Советы рәисе И.Х.Сагьдиев